Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл башкарма комитеты

КАРАР

5 февраль 2025 ел № 1

Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге территориясендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Берләшкән социаль фондының Әлмәт районындагы Клиент хезмәтенең (бүлек хокукларында) 2025 елның 22 гыйнварындагы 51-34-09/77 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Яңа Кәшер авыл башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, № 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37сум күләмендә 2025 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.

2.Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2024 елның 23 январендагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны торак пункт территориясендә Әлмәт районы, Яңа Кәшер ав., Тавабилов ур., 153 й., Бикасаз ав., Мәктәп ур., 1а й., адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә; «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кәшер авыл
башкарма комитеты җитәкчесе Л.М. Гыйниятуллина

Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авылы башкарма
комитетының
2025 елның 5 февралендәге
1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5 336,95 |
| 3 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 860,26 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 968,16 |
| Барлыгы | | 9 165,37 |

Яңа Кәшер авыл
башкарма комитеты җитәкчесе Л.М. Гыйниятуллина

Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авылы башкарма
комитетының
2025 елның 5 февралендәге
1 номерлы карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү | 3 129,04 |
| 3 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 207,90 |
| 4 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 860,27 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 968,16 |
| Барлыгы | | 9 165,37 |

Яңа Кәшер авыл
башкарма комитеты җитәкчесе Л.М. Гыйниятуллина